ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«6» 03 2026 ел № 65

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районың җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына таләпләр, аларны эшләү һәм раслау тәртибе турында " 2012 елның 22февралендәге 154 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2025-2035 елларга җылылык белән тәэмин итү схемаларын актуальләштерү турында гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) 2026 елның 6 мартына кадәр бастырып чыгарырга.

3. Гавами тыңлауларны уздыру урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан хакимият бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Балтач шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 42 йорт, актлар залы (3 кат), үткәрү датасы һәм вакыты: 2026 елның 7 апрелендә 13 сәгать 00 минутта.

4. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирү, гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар кабул итү адресы: Татарстан Республикасы, Балтач шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 42 йорт, Балтач район Советының оештыру бүлеге (3 нче кат), эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр.

5. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2026 елның 6 апреленә кадәр.

6. Татарстан Республикасы Балтач район Советының оештыру бүлегенә Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 19 мартындагы 242 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру тәртибе нигезендә гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Балтач муниципаль районы
Башлыгы Р.Р.Нотфуллин